МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.10.2021 Казан шәһәре 708

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 15 октябрендәге 7988 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 31 июлендәге 612 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 31 июлендәге 612 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 02.09.2014 №476, 07.06.2016 №317, 24.07.2017 №503, 07.05.2018 №352, 18.09.2018 №858, 12.11.2019 №991, 06.04.2020 №228, 13.07.2020 №499, 09.10.2020 №717, 18.06.2021 № 432 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2021 елның 1 октябрендәге 708
номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 31 июлендәге 612 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы бирү, аның гамәлдә булу чорын арттыру һәм алыштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы бирү, аның гамәлдә булу чорын арттыру һәм алыштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (кушымтада бирелә) расларга»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

Аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы бирү, аның гамәлдә булу чорын арттыру һәм алыштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламенты»;

1 бүлектә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы бирү, аның гамәлдә булу чорын арттыру һәм алыштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы бирү, аның гамәлдә булу чорын арттыру һәм алыштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.»;

1.4.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы)» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 1.4.4 – 1.4.8 пунктларын өстәргә:

«1.4.4. Мөрәҗәгать итүче телдән (шәхсән яки телефон аша) мөрәҗәгать иткән очракта Идарәнең (бүлекнең) консультация бирә торган белгече мөрәҗәгать

итүчеләргә кызыксындырган сораулар буенча тулы һәм нәзакатьле (корректлы) формада мәгълүмат бирә.

Телефон мөрәҗәгатенә җавап бирү мөрәҗәгать итүче шалтыраткан органның атамасы, телефоннан мөрәҗәгатьне кабул иткән белгечнең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булган очракта) һәм вазыйфасын әйтүдән башланып китә.

Әгәр Идарә (бүлек) бүлекчәсе белгече мөстәкыйль рәвештә җавап бирә алмый икән, телефон аша алынган мөрәҗәгать башка вазыйфаи затка адресланырга (күчерелергә) тиеш яисә мөрәҗәгать иткән затка кирәкле мәгълүматны алу мөмкинлеге булган телефон номеры турында хәбәр ителергә тиеш.

Җавапны әзерләү берникадәр вакыт таләп иткән очракта, ул мөрәҗәгать итүчегә эш итүнең түбәндәге вариантларын тәкъдим итә:

мөрәҗәгатьне язма рәвештә бәян итәргә;

консультацияләр өчен башка вакыт билгеләргә.

Идарә (бүлек) белгече дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандарт процедуралары һәм шартлары кысаларыннан чыга торган һәм турыдан-туры яки читләтеп кабул ителә торган карарга йогынты ясый торган мәгълүматларны бирергә хокуклы түгел.

Телефон аша мәгълүмат җиткерү вакыты 10 минуттан артмаска тиеш.

Мәгълүмат җиткерү гражданнарны кабул итү графигы нигезендә башкарыла.

1.4.5. Язмача мөрәҗәгать буенча Идарәнең (бүлекнең) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы белгече мөрәҗәгать итүчегә «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль законда (алга таба – 59-ФЗ номерлы федераль закон) билгеләнгән тәртиптә әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчасында) күрсәтелгән мәсьәләләр буенча белешмәләрне язмача формада җентекләп аңлата.

1.4.6. Бердәм порталда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүне (функцияләрне гамәлгә ашыруны) тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системалары турында» 2011 елның 24 октябрендәге 861 номерлы карары белән расланган «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү (функцияләр) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәдә каралган белешмәләр урнаштырыла.

1.4.7. Идарәнең (бүлекнең) көтү залларында дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актлар, шул исәптән мөрәҗәгать итүче таләбе буенча аңа танышу өчен бирелә торган Регламент урнаштырыла.

1.4.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны карау барышы хакында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) тарафыннан Бердәм порталдагы шәхси кабинет аша, шулай ук, мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, Идарәдән (бүлектән), телефон буенча, электрон почта аша алынырга мөмкин.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы бирү, аның гамәлдә булу чорын арттыру һәм алмаштыру).

## 2.2. Башкарма хакимият органының атамасы

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында социаль яклау идарәсе (бүлеге) йөзендә – мөрәҗәгать итүченең фактик яшәү урыны буенча.

## 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып таныклык (таныклык дубликаты) бирү (чорын арттыру) (таныклык (таныклык дубликаты) бирүдән (чорын арттырудан) баш тарту турында карар тора.

2.3.2. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү (чорын арттыру) турында карар алуның сайланган ысулы буенча рәсмиләштерелә һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә:

язма формада – почта адресы буенча;

электрон документ формасында – электрон почта адресына һәм мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталдагы, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына;

телефонга смс-хәбәр итеп.

## 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү күпбалалы гаилә таныклыгы бирү турындагы гаризаны (алга таба – гариза) теркәгәннән соң 10 эш көне эчендә башкарыла.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору законнарда каралмаган.

2.4.3. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү таныклык (таныклык дубликаты) бирү (чорын арттыру) (бирүдән (чорын арттырудан) баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

2.4.4. Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү мөрәҗәгать итүче әзер таныклыкны (таныклык дубликатын) алу өчен мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) Идарәгә (бүлеккә) электрон документлар рәвешендә җибәрелгән очракта, таныклык (таныклык дубликаты) мөрәҗәгать итүче үзенең фотосы белән мөрәҗәгать иткән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә.

## 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

Таныклыкны алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра (җибәрә):

1) гариза:

әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә кәгазьдә документ формасында;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы һәм Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, электрон формада (Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында һәм Бердәм порталда, гаризаны нинди дә булса башка төрле формада өстәмә тапшыру зарурлыгыннан башка гына) интерактив форманы тутыру юлы белән), әлеге пункт таләпләре нигезендә имзалап;

2) баланың тууын теркәү турындагы таныклыкның чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

3) чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән гаилә коруны теркәү турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

4) аерылышу турында чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

5) гражданлык хәле актларын теркәү органы яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениесе тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык күчермәсе;

6) белем алуына бәйле рәвештә ата-анасыннан читтә яши торган, 18 яшенә җитмәгән затлар өчен чит ил территориясендә бирелгән, Россия Федерациясеннән читтә белем алу турында документ күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе;

7) ир белән хатынның икенчесеннән документ, аның киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентның $1^1$ кушымтасында китерелгән, түбәндәгеләрне раслый торган:

аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык булуын;

шәхси мәгълүматларны органга яисә оешмага тапшырганда мөрәҗәгать итүченең алар исеменнән эш кылуга вәкаләтле булуын. Ирнең яисә хатынның имзасы Идарә (бүлек) белгече тарафыннан, нотариаль рәвештә яки Россия Федерациясе Гражданлык кодексының $185^1$ статьясының 2 пунктында һәм Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 53 статьясының 2 өлешендә күрсәтелгән оешмалар һәм учреждениеләр тарафыннан таныклана;

8) 3 х 4 см зурлыгындагы фото;

Таныклык дубликатын алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра (җибәрә):

1) таныклык дубликатын бирү турында гариза:

әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә кәгазьдә документ формасында;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге пункт таләпләренә туры китереп имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла);

2) әлеге Регламентның 2.5 пунктының 2-7 пунктчаларында күрсәтелгән документлар;

3) бозылган таныклык – бозылганы урынына алмашка таныклык дубликаты алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта.

Күпбалалы гаилә таныклыгының гамәлдә булу вакытын арттыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра (җибәрә):

1) аның гамәлдә булу вакытын арттыру турында гариза:

әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә кәгазьдә документ формасында;

Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге пункт таләпләренә туры китереп имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла);

2) әлеге Регламентның 2.5 пунктының 2, 5 һәм 7 пунктчаларында күрсәтелгән документлар;

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрен яклау вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең шәхесен таныклый торган документындагы белешмәләре исәпкә алыну язуы ИАБС расланган вакытта тикшерелә.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, юридик зат тарафыннан бирелгән документ документны биргән вәкаләтле затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, шәхси эшкуар тарафыннан бирелгән документ шәхси эшкуарның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, нотариус тарафыннан бирелгән документ нотариусның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш. Башка очракларда – гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмаларда, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алынырга мөмкин.

Таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

1) Идарәгә (бүлеккә) – кәгазьдә;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Бердәм порталда гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша электрон формада;

3) гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән Интернет челтәре аша;

4) күпфункцияле үзәк яки күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны аша.

Таныклык (таныклык дубликаты) бирү турындагы гаризаны Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша биргән очракта фото һәм бозылган таныклык (бозылганына алмашка таныклык дубликаты алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта) мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныклык дубликаты бирү турындагы белдерү алынганнан соң тапшырыла.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Документларның күчермәләре, әгәр дә алар законда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек) белгече яисә күпфункцияле үзәк белгече тарафыннан таныклана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гариза шулай ук Идарәдә (бүлектә) белгеч тарафыннан шәхсән кабул ителгәндә электрон рәвештә дә тутырылырга мөмкин, аңа мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон язуларны укый торган җайланмадан файдаланып кул куя.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Идарәгә (бүлеккә), күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урынына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасында документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

### 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар

белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча вәкаләтле оешмалардан түбәндәге белешмәләр алына:

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында;

Россия Федерациясе чикләрендә яшәү (тору) урыны буенча теркәлү яисә теркәлмәү турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында;

ата-ана хокукында чикләнү турында;

гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда баланы алу турында;

күпбалалы гаилә әгъзасының фамилиясен, исемен яки атасының исемен үзгәрткән затлар өчен – фамилиясен, исемен яки атасының исемен үзгәртү турында;

атаның яисә ананың вафат булуы турында;

билгесез югалган булуы турында;

нотариаль ышаныч кәгазе турында;

паспортның чынлыгы турында;

аталыкны билгеләү турында;

18 яшенә җитмәгән, белем алуына бәйле рәвештә ата-анасыннан аерым яши торган затлар өчен баланың белем алуы турында;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булмавы турында.

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.2. Идарә (бүлек) мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

1) Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;

2) күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә) төп документларның күрсәтелмәве;

3) мөрәҗәгать итүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе;

5) документларда хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы.

6) мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган һәм текстны төзәткән урыннар булуы;

7) хезмәт күрсәтү турындагы гаризаның һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның билгеләнгән таләпләрне бозып, электрон формада тапшырылуы;

8) Тапшырылган документларның яки белешмәләрнең хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү вакытына көчен югалтуы (мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, – хезмәт күрсәтүне сорап әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта).

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның яисә аның законлы вәкиленең яки ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан эш итү вәкаләте бирелгән затның документлар белән мөрәҗәгать итүе;P53

2) дөрес булмаган мәгълүматлары булган документлар тапшырылган очракта;

3) мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы территориясендә яшәгән урыны буенча теркәлмәве яки торган урыны буенча (яшәгән урыны буенча теркәлмәгән очракта) теркәлмәве;

4) мөрәҗәгать итүчедә салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булуы;

5) гаиләдә 18 яшькә кадәр өчтән азрак бала булуы;

6) мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документларның формасы һәм эчтәлеге буенча Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килмәве;

7) хезмәт күрсәтү хокукына ия булмавы;

8) ата-ана хокукыннан мәхрүм итү турында белешмәләр булуы (ата-ананың берсе (икесе) буенча);

9) баланың (балаларның) тулысынча дәүләт тәэминатында торуы турында белешмәләр булуы;

10) мөрәҗәгать итү вакытына беркетелгән һәм гамәлдә булган күпбалалы гаилә статусы турында белешмәләр булуы;

11) ата-ана хокукында чикләнү турында белешмәләр булуы;

12) баланың (балаларның) гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда баланың алынуы турында белешмәләр булуы.

2.8.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталда бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

### 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә

### 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми

### 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми

### 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.

### 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада

2.13.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгате гариза һәм документлар алынган көнне теркәлә.

2.13.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар почта юлламасы яки электрон документ (документлар пакеты) рәвешендә Идарәнең (бүлекнең) эш сәгате тәмамланганнан соң килсә, аларны алу көне булып киләсе эш көне санала. Әгәр гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) ял көне яки бәйрәм көнендә алынса, аларны алу көне булып киләсе эш көне санала.

### 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктчасының икенче абзацында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.14.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.14.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) яки күрсәтеп булмау мөмкинлеге

2.15.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;

Идарә (бүлек) бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

Идарәнең (бүлекнең) мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша электрон рәвештә гариза бирү мөмкинлеге.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Идарә (бүлек) белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуга прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы.

2.15.3. Мөрәҗәгать итүченең Идарә (бүлек) белгечләре белән бәйләнешкә керү күләме:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.15.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Идарә (бүлек) белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.15.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлык сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatarstan.ru), күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынында алынырга мөмкин.

2.15.6. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.15.7. Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гариза Идарәгә (бүлеккә) теркәлгән көннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Идарә (бүлек) белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр

2.16.1. Дәүләт хезмәтен экстерриториаль принцип буенча күрсәтү гаризаларны Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрү мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә гамәлгә ашырыла.

2.16.2. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар,

аларның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Идарә (бүлек), шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.16.3. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Бу очракта мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында ИАБС системасында исәпкә алыну язуын раслау юлы белән авторизация уза, электрон рәвештә интерактив формадан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тутыра.

2.16.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында тутырылган гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон рәвешләрен теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарәгә (бүлеккә) җибәрелә. ИАБС системасында авторизацияләнгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза мөрәҗәгать итүченең, гаризаны имзалау өчен вәкаләтле мөрәҗәгать итүче вәкиленең гади электрон имзасы белән имзаланган дип санала.

2.16.5. Гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән очракта, әлеге Регламентның 2.3 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә, мөрәҗәгать итүченең вәкиленә Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетка Идарә (бүлек) җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ формасында җибәрелә.

2.16.4. Электрон документлар түбәндәге форматларда тапшырыла:

а) xml - формалаштырылган документлар өчен;

б) doc, docx, odt - формулалары булмаган, текстлы эчтәлектәге документлар өчен (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш);

в) xls, xlsx, ods - исәпләмәләре булган документлар өчен;

г) pdf, jpg, jpeg - формулаларны һәм (яки) график сурәтләрне дә үз эченә алган (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш), шулай ук график сурәтләре булган документларны да кертеп, текстлы эчтәлектәге документлар өчен.

Документның үз оригиналын сканер аша уздыру юлы белән электрон документны формалаштыру рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), ул 300 - 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә документ оригиналы ориентациясен саклап гамәлгә ашырыла, түбәндәге режимнарны кулланып:

«каралы-аклы» (документта график сурәтләр һәм (яки) төсле текст булмаган очракта);

«соры төсмерләрдә» (документта төсле график сурәтләрдән аерыла торган график сурәтләр булган очракта);

«төсле» яки «төсне тулы дәрәҗәсендә тапшыру режимы» (документта төсле

график сурәтләр яисә төсле текст булган очракта);

чын нөсхәдәге барлык аутентик билгеләрне, атап әйткәндә: затның график имзасын, мөһерне, бланк чатындагы штампны саклап;

файллар саны һәркайсында текстлы һәм (яки) графикалы мәгълүматлар булган документлар санына туры килергә тиеш.

2.16.5. Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

документны һәм документтагы битләр санын идентификацияләү мөмкинлеген;

өлешләргә, бүлекләргә, кисәкләргә (кискәчләргә) бүленгән документлар өчен эчтәлек буенча һәм (яки) текстта булган рәсемнәргә һәм таблицаларга күчү мөмкинлеген.

xls, xlsx яки ods форматларында тапшырылырга тиешле документлар аерым электрон документ рәвешендә формалаштырыла.

2.16.6. Мөрәҗәгать итүчеләрне Идарәгә (бүлеккә) кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Идарәнең (бүлекнең) телефон номеры аша телефон элемтәсе аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Идарәдә (бүлектә) билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итү көннәре, вакыты һәм урыннары.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу барышында күрсәтелгән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган вакытта, мөрәҗәгать итүчегә үзе тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән, әгәр дә ул кабул итү өчен билгеләнгән вакыттан соң 15 минут узгач килмәсә, алдан язылуның гамәлдән чыгарылачагы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яки Идарәнең (бүлекнең) телефон номеры буенча алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

2.16.7. Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.16.8. Гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелергә мөмкин.

Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы гариза биргәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе электрон формада бирелә.»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре.

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә дә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны тутыру өлешендә дә;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) мәгълүматлар алу, ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, Мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат алу;

гариза формалаштыру;

гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәүгә алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу;

гариза карау барышы турында мәгълүмат алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

дәүләт хезмәтен күрсәтә торган Идарә (бүлек) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) яисә Идарәнең (бүлекнең) вазыйфаи затлары яки дәүләт граждан хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү.

Гаризаны карау барышы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алу, авторизацияләнү шарты белән, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетта гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта үз инициативасы буенча шәхси кабинетта электрон гаризаның статусын, шулай ук алга таба башкарылачак гамәлләр турында мәгълүмат карау мөмкинлегенә ия.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләр җибәрелә:

а) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итү һәм теркәү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының башлану факты турындагы белешмәләрне, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүне тәмамлау датасы һәм вакыты турындагы белешмәләрне яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән нигезле баш тартуны үз эченә алган белдерү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре

турында белдерү, анда дәүләт хезмәте күрсәтү турында уңай карар кабул ителүе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе алу мөмкинлеге турында белешмәләр яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезле баш тарту була.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән гаризаны тутыру өлешендә дә

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон, почта, электрон почта аша, техник мөмкинлек булганда, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша һәм (яки) Идарәгә (бүлеккә) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Идарә (бүлек) белгече шәхсән, телефон, почта, электрон почта ярдәмендә, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча да, гариза бланкы бирә һәм, зарурлык булганда, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза тутыру өлешендә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән гаризаны тутыру өлешендә дә.

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәк (http://mfc16.tatarstan.ru/) сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

3.3. Гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында гаризаны, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның күчермәләрен теркәп, Идарәгә (бүлеккә) тапшыра.

Идарәгә (бүлеккә) почта аша, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша, электрон почта буенча, Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алынган гариза мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителгән гариза һәм документларны карау өчен билгеләнгән тәртиптә карала.

Почта аша заказлы хат итеп яисә электрон формада җибәрелгән гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) гомуми тәртиптә карап тикшерелә.

Мөрәҗәгать итүче, гаризаны Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада тапшыру өчен, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр

күрсәтү порталында авторизацияләү уза;

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга куя);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга куя);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.5 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала. Мөрәҗәгать итүчеләр гаризаны Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрә ала.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Формалаштырылган гаризаны форматы-мантыйгы ягыннан тикшерү мөрәҗәгать итүче гаризаның электрон формасындагы барлык юлларны тутырганнан соң гамәлгә ашырыла. Гаризаның электрон формасындагы кырларны төгәлсез тутыру очрагы ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмат җиткереп, хәбәр ителә.

Гаризаны формалаштырганда мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) гаризаның һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларның күчермәләрен ясау һәм аларну саклау мөмкинлеге;

б) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

в) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

г) ИАБС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, ИАБС системасында урнаштырылган һәм Бердәм порталда, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр электрон гариза формасы кырларын тутыру;

д) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

е) мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында бер елдан азрак булмаган чорда үзе

элегрәк тапшырган гаризаларны, шулай ук кимендә 3 ай эчендә өлешчә формалаштырган гаризаларны карау мөмкинлеге.

Формалаштырылган һәм имзаланган гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар Идарәгә (бүлеккә) Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелә.

3.3.1.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы заты аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында, әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар теркәп, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына язмача гариза һәм документлар тапшыра ала.

Күпфункцияле үзәкнең гаризаларны һәм документларны кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза һәм документлар.

3.3.1.2. Күпфункцияле үзәк белгече гариза һәм документларны Идарәгә (бүлеккә) җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Идарә (бүлек) белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында, үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарәгә (бүлеккә) җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.2. Идарә (бүлек) белгече дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Идарә (бүлек) белгече өчен электрон гаризаны алу мөмкинлеге «Татарстан Республикасы Халыкның социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында тәэмин ителә.

Идарә (бүлек) белгече:

Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан электрон гаризалар булу-булмавын көненә 2 тапкырдан ким булмаган ешлыкта тикшерә;

алынган гаризаларны һәм теркәлгән документлар рәвешләрен карый;

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 2 нче кушымтасы);

гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, алынганда беркетелгән номеры турында тамгалап, мөрәҗәгать итүчегә язу бирү – мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта;

гаризаны теркәү датасы һәм алынганда кергән номеры турындагы белдерүне җибәрү – гариза почта аша һәм (яки), Интернет челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып юлланган очракта;

гаризаны теркәү турындагы белдерүне Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрү – гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән очракта.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булган очракта (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә), Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре турында телдән хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, барлык документларны аңа кайтарып бирә. Гаризаны һәм документларны почта аша һәм (яисә), Интернет челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән алганда, Идарә (бүлек) белгече гаризаны һәм документларны, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен язмача аңлатып, кайтарып бирә.

Гаризаны Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша биргән очракта, гаризаны теркәүдән баш тарту турында белдерү мөрәҗәгать итүченең Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә, – гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) кергән көнне;

гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яисә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша килгәндә, – гариза һәм документлар Идарәгә (бүлеккә) килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Идарәнең (бүлекнең) эш сәгате тәмамланган вакытта алынган очракта, аннан соңгы эш көнендә;

гариза һәм документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Идарәнең (бүлекнең) ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гаризаларны теркәү журналында гаризаны теркәү язуы, мөрәҗәгать итүчегә документларны алу кэгазе яисә кайтарып бирелгән документлар, документларны кабул итүдән баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү.

3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү

3.4.1. Идарә (бүлек) белгече вәкаләтле органнардан электрон рәвештә түбәндәгеләр турында мәгълүматлар ала:

баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында;

өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында.

3.4.2. Идарәдә (бүлектә) таныклык (таныклык дубликаты) бирү карарын кабул итүгә кирәкле мәгълүматлар булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече, шул исәптән

электрон рәвештә дә, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында;

Россия Федерациясе чикләрендә яшәү (тору) урыны буенча теркәлү яисә теркәлмәү турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында;

ата-ана хокукында чикләнү турында;

гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда баланы алу турында;

күпбалалы гаилә әгъзасының фамилиясен, исемен яки атасының исемен үзгәрткән затлар өчен – фамилиясен, исемен яки атасының исемен үзгәртү турында;

атаның яисә ананың вафат булуы турында;

билгесез югалган булуы турында;

нотариаль ышаныч кәгазе турында;

паспортның чынлыгы турында;

аталыкны билгеләү турында;

18 яшенә җитмәгән, белем алуына бәйле рәвештә ата-анасыннан аерым яши торган затлар өчен баланың белем алуы турында;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булмавы турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза алынган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать.

3.5. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү (вакытын арттыру) турында карар кабул итү

3.5.1. Идарә (бүлек) белгече әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, алынган белешмәләр һәм әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда алынган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле буларак катнашучы затның яисә мөрәҗәгать итүче вәкаләт биргән затның вәкаләтләрен тикшерә;

әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 2.1 кушымтасына туры килә торган форма буенча таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар проектын электрон формада рәсмиләштерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган көннән ике эш көне эчендә, әмма гаризаны теркәгәннән соң җиде эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында электрон рәвештәге карар проекты.

3.5.2. Идарә (бүлек) җитәкчесе таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турындагы карар проектын карый һәм көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалый һәм Идарә (бүлек) белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турындагы карар проекты имзалау өчен җибәрелгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: имза салынган һәм Идарә (бүлек) белгеченә җибәрелгән таныклык (таныклык дубликаты) бирү (вакытын арттыру) (бирүдән (вакытын артырудан) баш тарту) турында карар.

3.5.3. Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (язмача формада почта адресы буенча, электрон формада электрон почта адресы буенча, телефонга смс-хәбәр юллап, Бердәм порталда яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинет аша) таныклык (таныклык дубликаты) бирү (вакытын арттыру) (бирүдән (вакытын арттырудан) баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында хәбәр итә. Гариза электрон документлар рәвешендә яки Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша бирелгән очракта, Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә фото кирәклеге турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турындагы карар проекты имзаланган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.5.4. Идарә (бүлек) белгече таныклык (таныклык дубликаты) бланкын рәсмиләштерә.

Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) Идарәгә (бүлеккә) электрон документлар рәвешендә яисә Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән очракта, таныклык (таныклык дубликаты) Идарәгә (бүлеккә) фото тапшырылганнан соң рәсмиләштерелә һәм мөрәҗәгать итүченең фото белән мөрәҗәгать иткән көннән соңгы икенче эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура таныклык (таныклык дубликаты) бирү турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Электрон документлар рәвешендә яки Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша гариза биргәндә – мөрәҗәгать итүче үзенең фотосы белән мөрәҗәгать иткән көндә.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәсмиләштерелгән таныклык бланкы.

3.5.5. Идарә (бүлек) җитәкчесе рәсмиләштерелгән таныклык бланкын имзалый һәм Идарә (бүлек) белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура рәсмиләштерелгән таныклык (таныклык дубликаты) бланкы имза кую өчен җибәрелгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәсмиләштерелгән, Идарә (бүлек) җитәкчесе имза салган таныклык (таныклык дубликаты) бланкы.

3.5.6. Идарә (бүлек) белгече:

таныклыклар (таныклыкларның дубликатларын) бирү кенәгәсендә язу терки (3

нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә рәсмиләштерелгән һәм Идарә (бүлек) җитәкчесе имзалаган таныклыкны (таныклык дубликатын) бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Идарә (бүлек) җитәкчесе таныклыкның (таныклык дубликатының) рәсмиләштерелгән бланкына кул куйган көнне гамәлгә ашырыла. Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) Идарәгә (бүлеккә) электрон документлар рәвешендә яисә Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән очракта, күпбалалы гаилә таныклыгы мөрәҗәгать итүче фотосы белән мөрәҗәгать иткән көннән соңгы икенче эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: таныклыклар бирү кенәгәсендә язу, бирелгән таныклык (таныклык дубликаты).

3.6. Техник хаталарны төзәтү

Техник хатаны төзәтү, таныклыкны (таныклык дубликатын) теркәп, әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына туры килә торган форма буенча мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныклыктагы (таныклык дубликатындагы) техник хатаны төзәтү турындагы гариза тапшырылган очракта гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән яки ышанычлы заты аша Идарәгә (бүлеккә) яисә күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша Идарә (бүлек) тарафыннан бирелгән таныклык (таныклык дубликаты) бирү турындагы карарда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм ялгышларны төзәтү турында язмача гариза тапшыра.

Гаризаны күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша тапшырган очракта, күпфункцияле үзәкнең гаризаларны кабул итә торган белгече:

күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра;

Идарәгә (бүлеккә) техник хаталарны төзәтү турында гариза җибәрә.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедура күпфункцияле үзәкнең эш регламентында һәм үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, идарәгә (бүлек) техник хаталарны төзәтү турында гариза җибәрү.

3.6.1. Идарә (бүлек) белгече:

техник хатаны төзәтү турынданы гаризаны кабул итә һәм гаризаларны теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 2 нче кушымтасы);

Таныклык (таныклык дубликаты) бирү (вакытын арттыру) турында карар рәсмиләштерә;

таныклык (таныклык дубликаты) бирү турындагы карарны Идарә (бүлек) җитәкчесенә җибәрә.

таныклык (таныклык дубликаты) бланкын үзгәртеп рәсмиләштерә;

үзгәртеп рәсмиләштерелгән таныклыкны (таныклык дубликатын) имза кую өчен Идарә (бүлек) җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән,

теркәлгән гариза, документлар кабул итүдән баш тарту турында карарны, дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турындагы карарны, таныклыкның (таныклык дубликатының) үзгәртеп рәсмиләштерелгән бланкын имзалау өчен Идарә (бүлек) җитәкчесенә җибәрү.

3.6.2. Идарә (бүлек) җитәкчесе үзгәртеп рәсмиләштерелгән таныклык (таныклык дубликаты) бланкын имзалый һәм аны Идарә (бүлек) белгеченә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура рәсмиләштерелгән таныклык (таныклык дубликаты) бланкы имза кую өчен җибәрелгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган таныклык (таныклык дубликаты) бланкы

3.6.3. Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчене гаризада күрсәтелгән ысул белән (язмача формада почта адресы буенча, электрон формада электрон почта адресы буенча, телефонга смс-хәбәр юллап, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинет аша) үзгәртеп рәсмиләштерелгән таныклык (таныклык дубликаты) алу өчен чакыра.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчене үзгәртеп рәсмиләштерелгән таныклыкны (таныклык дубликатын) алу өчен чакырту.

3.6.4. Идарә (бүлек) белгече:

таныклыклар бирү кенәгәсендә язу терки (әлеге Регламентка 3 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә үзгәртеп рәсмиләштерелгән таныклык (таныклык дубликатын) бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: таныклыклар бирү кенәгәсендә язу, бирелгән үзгәртеп рәсмиләштерелгән таныклык (таныклык дубликаты).»;

Регламентның 6 нчы бүлеген гамәлдән чыккан дип танырга;

Регламентка 1 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы бирү, аның гамәлдә булу чорын арттыру һәм алыштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 1 нче кушымта»;

Регламентка $1^1$ кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы бирү, аның гамәлдә булу чорын арттыру һәм алыштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына $1^1$ кушымта»;

Регламентка 2 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы бирү, аның гамәлдә булу чорын арттыру һәм алыштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 2 нче кушымта»;

Регламентка $2^1$ кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпбалалы гаилә статусын билгеләү

(Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы бирү, аның гамәлдә булу чорын арттыру һәм алыштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына $2^1$ кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар формасы

____________»________«___________
карар кабул итүгә вәкаләтле орган исеме

________________________________________

________________________________________
*Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, ата исеме, адресы*

________________________________________
*Гаризаның номеры һәм гаризаны теркәү датасы*

КАРАР

« «/» «

«____________«_ №«__________«

________________________________________»__________«______________________________
*(башкарма хакимият органының исеме)*

Гаризаны һәм тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча

<< >>____<< >>____<< >>
(мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А.)

__________________________<< >> << >>_____________________________
*(гаризаның номеры һәм гаризаны теркәү датасы)*

«Күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы бирү, аның гамәлдә булу чорын арттыру һәм алыштыру)» буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында, түбәндәгеләр нигезендә: ____________________________________________
*(хезмәт күрсәтүне җайга сала торган РФ субъекты норматив хокукый акты, аның номеры һәм датасы күрсәтелә)*

**карар кабул ителде** << >> №<< >> яки << >>
<< >>_ 20___ елның ________________ кадәр.

Күпбалалы гаилә таныклыгын Сез << >> ала аласыз.

<< >> << >>
Карар кабул итүгә вәкаләтле затның вазыйфасы
Фамилия, исем, ата исеме

________________________________________

| Электрон имза сертификаты турында белешмәләр |
|---|

Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән/хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар формасы

______________»_______«___________
карар кабул итүгә вәкаләтле орган исеме

_______________________________________

_______________________________________
*Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, ата исеме, адресы*

_______________________________________
*Гаризаның номеры һәм гаризаны теркәү датасы*

КАРАР

« «/» «

«____________«_ №«__________«

________________________________»__________«________________________________
*(башкарма хакимият органының исеме)*

Каралган гариза нәтиҗәләре буенча
<< >>____<< >>____<< >>
(мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А.)

________________________<< >> << >>________________________
*(гаризаның номеры һәм гаризаны теркәү датасы)*

«Күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы бирү, аның гамәлдә булу чорын арттыру һәм алыштыру)» буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш турында << >>/<< >> **карар** кабул ителде, түбәндәгеләр нигезендә:
<< >> << >> << >>
<< >> << >> << >>
<< >> << >> << >>
<< >> << >> << >>
<< >> << >>
*(баш тарту сәбәпләрен аңлату)*

Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез: << >>
_______________________________________________________________
*(хезмәт күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук, булган очракта, башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә).*

Әлеге җитешсезлекләрне бетергәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән Сез вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.
Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.
_______________________________________________________________.

Карар кабул итүгә вәкаләтле затның вазыйфасы Фамилия, исем, ата исеме
<< >> << >>

Электрон имза сертификаты турында белешмәләр «;

Регламентка 3 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы бирү, аның гамәлдә булу чорын арттыру һәм алыштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 3 нче кушымта»;

Регламентка 4 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы бирү, аның гамәлдә булу чорын арттыру һәм алыштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 4 нче кушымта»;

Регламентка 5 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы бирү, аның гамәлдә булу чорын арттыру һәм алыштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 5 нче кушымта»;

Регламентка (белешмәлек) кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпбалалы гаилә статусын билгеләү (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгы бирү, аның гамәлдә булу чорын арттыру һәм алыштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына (белешмәлек) кушымта».